КАЯ БАРАБЫЗ?
«ВТ» хәбәрчесенең дөньядагы вакыйгаларга карашы
> 2

ЯҢАДАН КАЙТУ
Казанда Гадел Кутуйга истәлек тактасы ачтылар
> 2

СҮНМӘС УТ
Актаныш районының электр челтәрләре – 50 ел
> 3

УНЫНЧЫ ЖИҢУ
Көрәшче Раил Нургалиев Татарстан чемпионатында иң күп тапкыр батыр калган егетләр сафына кушылды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 176 (29143) | Чәршәмбе | 29 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

БЕРДӘМЛЕК ҺӘМ ЭШ

Татарлар җыелган җирдә

350гә якын катнашучы, 3 көн һәм «Туган тел» җыры. Казанда «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы узды. Россия генә түгел, чит илләрдә яшәүче эре татар эшмәкәрләрен дә берләштерүче әлеге җыенда эш турында гына түгел, татарларга хас бердәмлек һәм туган тел турында да сөйләштеләр.

Быел «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре форумы» уналтынчы тапкыр үткәрелде. Аны Бөтендөнья Татар конгрессы Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә палатасы белән берлектә оештыра. Җыенның пленар утырышында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Быел Казанда узган чарага илнең 40ка якын төбәгеннән, 10га якын һәм ерак чит илдән эшкуарлар килде. Тәүге тапкыр Перу, Испания кебек чит илләрдән дә милләттәшләребез бар иде.

– Безнең төп бурычыбыз – татар эшкуарларын берга җыю, аларны узара таныштыру һәм яңа үрләр яуларга ярдәм итү, – диде Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья Татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразыев. – Форум елдан-ел камиллашә. Аның эчтәлеге дә замана таләпләренә яраклаштырыла. Сез барыгыз да татар оешмалары булган өлкәләрдә, илләрдә яшисез. Милләттәшләребез белән узара ярдәмләшеп яшәсәгез, бик рәхмәтле булыр идек. Без сезгә эшегезне Татарстанда җәелдерергә булышырга да әзер.

Ә бердәм халык көтелә. Моны эшкуарлар гына түгел, гомумән, татар халкы раслап күрсәтте инде. Җыенга быелның маенда Курган өлкәсендә көчле янгын чыгу аркасында тулысынча диярлек янып көлгә әйләнгән Йолдыз (Әчкен) авылы халкы да килгән иде. Алар фаҗигане беренче сәгатьләреннән үк ярдәм кулы сузган татар эшкуарларына, бөтен татар дөньясына рәхмәт белдерде.

– Авылда 228 йорт янды. Мәчет, мәктәп, мәдәният йорты һәм бер урам гына калды, – дип искә алды ул коточкыч вакыйгаларны «Урал арьягы татарлары» иҗтимагый оешмасы рәисе Марат Юнусов. – Әнә шундый кыен чакта милләттәшләребез ярдәм кулы сузды. Бүген авылда йөз яңа йорт төзелә. Аларның 40ы яңа елга кадәр үк тапшырылачак. Тагын 36сы гыйнварда әзер булачак. Калганнарын язга өлгертәчәкбез. Барлыгы 200 йорт өчен сертификат бирелде. Шуның яртысына авыл халкы йорт салу телəген белдерде. Калган сертификатларга шәһәрдә фатир сатып алдылар. Тик авылның яңадан тергезелүен күреп, хәзер салада үз акчаларына йорт җиткерә башлаучылар да күп. Татарстанга бик зур рәхмәт. «Татнефть» оешмасы гына да безгә 18 әзер йорт алып килде. Без татар булуыбыз, милләтебез, халкыбыз белән чын мәгънәсендә горурланабыз.

Эльвира һәм Калимулла Миңнегәрәевләр республика нефтьчеләре салып биргән йортта өй туе үткәргән дә инде.

– Фаҗигане беренче көненнән үк Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре килеп, хәлебезне белеште, бөтен кирәк-яракны язып алдылар. Ашау-эчү, кием-салым белән булыштылар. Татарстанның безне ташламаячагын аңладык. Тиз арада төзелеш эшләре башланды, гуманитар ярдәм даими рәвештә килеп торды. Яңа йортларыбызга карап туймаслык, алар бик матур, җылы. Бөтен авыл халкы исеменнән шәхсән Рөстәм Нургали улына һәм бөтен республика халкына рәхмәт әйтерә дип килдек, – диде күз яшьләре аша гаилә башлыгы.

Бүген Йолдыз авылында 329 кеше яши. Әле авылдашлар саны тагын да артачак, дип якты киләчәккә өметләнә йолдызлылар.

‹ Ахыры 2 нче биттә ›

tatarstan.ru

Йолдыз укучылары Казаннан истәлекле фото белән кайтып китте.

Фикер

Ринат НАСЫЙРОВ, республиканың дәүләт бүләге иясе, Төмәндәге «Бәрәкәт – Благо» хәйрия фонды рәисе:

– Республика җитәкчелеге тырышлыгы белән соңгы елларда читтә яшәүче милли оешмалар үзләрен Хөкүмәт кулы астында эшләгән кебек хис итә. Татарстанда мал да табабыз. Дәүләт оешмасыма ул, муниципаль дәрәҗәдәге учреждениеме, бүген Татарстандагы теләсә кайсы оешма безнең татарлыкны таныш, яшел юл күрсәтә. Шуңа күрә тиз һәм җиңел эшлибез. Элек без ерак тоела идек. Хәзер бик якын итәләр. Бу эшлекле мөнәсәбәтләр белән берррәттән, мәдәният, мәгариф, милли киемнәр кебек өлкәләргә дә кагыла. Системалы эш бар. Алла боерса, аның нәтиҗәсе да уңай булачак. Бүген Төмән өлкәсендә 26 татар оешмасы, 41 татар мәктәбе эшли. Без – кайда гына яшәсәк тә, тирән, җирле халык. Җырлап, биеп кенә йөри торган халык түгел икәнен Йолдыз авылы мисалында да күрсәтә алдык. Татарлар бер-берсенә бик нык ышана.

Керем-чыгым хисабы

Бу елның 10 аенда Татарстанның берләштерелгән бюджетына кергән керем күләме, былтыргы күрсәткечкә караганда, 11,3 процентка арткан. Шулай итеп быелгы күрсәткеч 384,7 млрд сумны тәшкил итә.

Республиканың Финанс министрлыгы белгечләре Татарстанның берләштерелгән бюджеты керемнәренең иң әһәмиятле өч чыганагын да атады. Болар табышка салым (керемнең 38 проценты), НДФЛ (28 процент), оешмаларның мөлкәтенә салым (10 процент).

10 ай эчендә салым һәм салым булмаган керемнәр хисабына җыелган суммадан 633 млрд сум федераль казнага күчерелгән. Барлык сумманың 62 проценты бу.

Бюджет чыгымнарына килгәндә, 10 ай эчендә аның күләме 423 млрд сумга җиткән. Иң күп чыгымнар таләп иткән өлкә – социаль-мәдәни тармак (барлык чыгымнарның 55 проценты). Шулардан иң күп акча мәгарифкә (119 млрд сум) һәм сәламәтлек саклауга тотылган (83,5 млрд сум).

10 ай эчендә республика федераль акчаның 91 процентын үзләштергән. Юл, индустриаль парклар төзү, авыл территорияләрен үстерү, торак-коммуналь хуҗалык, мәктәп, сәламәтлек саклау тармакларына тотылган акча бу.

3 меңгә арта

Хезмәткә түләүнең минималь күләме (МРОТ) 18,5 процентка артачак. Россия Президенты Владимир Путин бу җәһәттән законга кул куйган. Аның нигезендә, киләсе елның 1 гыйнварыннан МРОТ күләме аена 3 мең сумга күбәеп, 19242 сумга (әлегә аның күләме – 16242 сум) җитәчәк. Документ хокукый мәгълүматлар рәсми порталына урнаштырылган.

Моннан тыш 2025 елдан, МРОТның уртача хезмәт хакына нисбәтен арттырып, 42дән 48 процентка җиткерү күздә тотыла.

Күбрәк оча башлаганнар

Казан аэропорты язгы-җәйге чорда (26 марттан 28 октябрьгә кадәр) 3,5 миллионга якын пассажирга хезмәт күрсәткән. Узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 30,8 процентка зуррак сан бу.

«Татар-информ» хәбәренә караганда, шушы вакыт эчендә барлыгы 28,5 меңнән артыграк (узган елдагыга караганда 18 процентка күбрәк) рейс ясалган. Әчке рейсларда пассажирлар саны 19,9 процентка арткан.

Суз уңаеннан, киләсе елда Казан аэропортының өченче терминалын төзи башлаячаклар. Ул хәзерге терминаллардан 2 тапкыр зуррак булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Инвалидлар ункөнлеге

Көчле рухлылар

Алар рухлары белән көчле! Язмыш ничек кенә сынаса да, тормыш авырлыклары алдында югалып калмаска көч тапкан кешеләр купләргә үрнәк. Татарстанда физик мөмкинлеге чикләнгән 279 мең кеше яши, шуларның 17,5 меңе – сабыйлар. Аларга каралган ярдәм чаралары турында Министрлар Кабинетында узган брифингта Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү министры Эльмира Зарипова сөйләде.

– Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә ел әйләнәсендә ярдәм итәргә тырышабыз. Аларның тормышлары яхшырсын, уңайлы шартлар тудырылсын өчен республикада күп эшләр башкарыла. Инвалидлар ункөнлеге чорында исә аларга игътибар тагын да арта, – ди министр.

2011–2020 елларда Татарстанда «Уңайлы мохит» программасы буенча 921 объект җиһазланган. Ел ахырына кадәр тагын 25 объект яңартылачак. Сүз уңаеннан, яңа төзелә торган йортларда, сәүдә үзәкләре инде алдан ук физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә җайлаштырыла.

Эльмира Зарипова фикеренчә, кеше ярдәменә мохтаҗ балаларны тормыш алып барырга иртәрәк өйрәтергә кирәк. Бу уңайдан «Демография» илкүләм проектлары ярдәм итә. Шуның кысасында интернатта яшәүче балалар «Идел» тернәкләндерү үзәгенә барып, үзләре генә яшәргә өйрәнәләр. Әле күптән түгел бер гаиләдә яшәүче малайны да алып килгәннәр. Менталь тайпылышлары булган бу сабыйны әнисенең моңа кадәр бер сәгатькә дә ялгыз калдырганы булмаган.

– Әнисе баласының хәлен ярты сәгать саен белешеп торды. Бик курыккан иде. Ул бала бу үзәктән китеп барып ашарга алып кайтырга, үзенә ризык әзерләргә, җыештырырга өйрәнеп чыкты. Республиканың һәр районында тормышка әзерли торган көндезге булекләр эшли. Әти-әниләрнең гел янәшә була алмауларын да онытмыйк, – ди Эльмира Зарипова.

Министр инвалидларны эшкә урнаштыру турында да сөйләде. «Благодарю» коммерцияле булмаган социаль оешмасы физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне эшкә урнаштыруда үз өлешен кертә икән. Быел аларда өйрәнү үткән сигез баланың җидесе эшкә кергән. Республикада 33 мең инвалид эшкә яраклы. Быелның 10 аенда үз эшләп 1660 кеше мөрәҗәгать иткән, шуның 1310ы үзенә яраклы эш тапкан. 2023 елда Әлмәт, Алабуга, Чистай, Казан шәһәрләрендәге төрле оешмалар да 234 кешене ашлы иткән.

Министр дәүләттән ярдәм алып, үз эшен ачкан кешеләр турында да сөйләде. Алар бер тапкыр бирелә торган 145 мең сум субсидияне алып, эш башлап җибәргән. Быел бу мөмкинлектән 14 инвалид файдаланган.

Ахыры 3 нче биттә ›

Сүзгә-сүз

pnp.ru

Анатолий АРТАМОНОВ, Федерация Советының Бюджет һәм финанс базарлары буенча комитет рәисе:

Мин һәрчак әйтә килам: без ташламалы ипотека мәсьәләсендә уйлап эш итмибез. Мондый ипотека Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләрдә яшәүчеләр өчен түгел, ә халкы яхшы тормыш эзләп читкә киткән төбәкләрдә кертелергә тиеш. Бу бирәә яшәүчеләрне шушы җирлектә саклап калу өчен кирәк.

РОССИЯДӘ – ҮЗМӘШГУЛЬЛӘР

Үзмәшгульләр	15 миллион
Керем күләме	2,9 триллион сум
Уртача яшь	35
42% »	хатын-кызлар
58% »	ир-атлар

*Салым федераль хезмәте мәгълүматлары нигезендә

Чирләмә!

Узган атнада Россиядә 79 меңнән артыграк кешенең коронавирус йоктыруы ачыкланган. Роспотребнадзор хәбәр иткәнчә, чирләүчеләр саны 100 мең кешегә 54,47 күрсәткечен тәшкил итә. Бу – алдагы атнадагыга караганда 32,8 процентка зуррак сан. Шулай ук грипп һәм ОРВИ йоктыручыларның күбәюе күзәтелә.

Ведомство башлыгы Анна Попова искәртеп узганча, прививка ясату бигрәк тә иммунитеты начар булган өлкәннәрдә, балалар һәм йөкле хатын-кызларда авыруны кисәтү, организмда өзеклекләргә юл куймау мөмкинлеге бирә.

Татарстанда да чирләүчеләр арта. 20–26 ноябрь чорында 224 сырхау (алдагы атнадагыга караганда 19,1 процентка күбрәк) хастаханәгә озатылган. Ә 13–19 ноябрьдә мондыйлар саны 188 булган.

Соңгы мәгълүматларга караганда, республикада коронавирус йоктыруның 210591 очрагы теркәлгән. Пандемия башланганнан бирле әлеге чирдән 2010 кеше вафат булган. Бу елның гыйнварыннан бирле үлем-китем очраклары юк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ ЧИР ҺӘМ КРИЗИС БЕЛӘН КӨРӘШӘ

Планетаның төп фабрикасы һәм чимал базарына әйләнгән Кытай зур проблемалар белән көрәшә. Бердән, илдә балалар арасында сәер рәвештә пневмония тарала. Коронавируска каршы аеруча рәхимсез ысуллар кулланып көрәшкән кытайлар йогышлы чирләрдән котыла алмый. Америка телевидениесе хәбәрләренә караганда, хәл ярыйсы ук катлаулы. Бөтендөнья сәламәтлек оешмасы бу уңайдан чир таралу хакында мәгълүмат сорап Пекинга рәсми хат юллады. Чит ил белгечләре вазгыятьне даими тикшереп торырга кирәк дип саный, әмма үпкә чире таралу зур глобаль куркыныч турында сөйләмидер дигән фикер белдерәләр. Мөгаен, алар ковидка ияләнеп бетә алмыйдыр, артык каты саклану һәм вакцина белән мавыгу ил халкының иммунитетына зыян салган булырга тиеш.

Кытайларның икенче бәласе – гигант төзелеш компанияләренең дефолты нәтиҗәсе буларак башланырга торган зур кризис. Алар бар көченә икътисад түнтәрелешен тормозга куеп торырга азаплана. Кытай компартиясенең икътисад мәсьәләләрен карарга тиешле өченче пленумы көтелә иде, ул кичектерелә. Югары җитәкчелек хәлиткеч карарлар кабул итү өчен вакыт таләп ителә дип саный, күрәсең.

Кытайның Милли статистика бюросы дүшәмбе көнне елның беренче ун ае нәтиҗәләрен игълан итте. Сәнәгать предприятиеләренең табышы, үткән ел белән чагыштырганда, 7,8 процентка кимегән. Дәүләт компанияләре табышы 9,9 процентка азайган. Чит ил компанияләре 10,2 процент табыш югалтканнар. Экспорт та, импорт та сигезенче ай рәттән кими.

Төзелеш тармагын аякта тотып тору өчен, Кытайда ноябрь аеннан торак төзелешенең дәүләт программасы гамәлгә ашырыла башлады. Моның өчен 1 триллион юань (137 миллиард доллар) акча бүленде. Девелоперлар бу акчаны банклар аша төп ставкадан ике тапкыр түбәнрәк процент белән алачак. Программа төзелеш тармагын кризистан чыгарыр дип әйтү кыен, чөнки төзелгән йортлар сатылмый, ә болай да бурычка баткан илнең әҗәтләренә яңа әҗәт өстәр. Чин икътисады өстендә болай да күтәреп булмаслык бурычлар йөге эленеп тора. Җитештерүне арттыру өчен хезмәт хакларын һәм халыкның керемнәрен үстерергә кирәк. Россия, әйтик, 2–3 процентлык үсеш белән дә үзен яхшы хис итә ала, әмма кытайларга үсешнең гадәттән тыш темплары таләп ителә. Кискен югары темплар белән үсеш булмаса, бурычларны түли алмыйча, дефолт игълан итәсе була. Керемнәрне үстерү яңа бурычлар туплануга китерәчәк. Алар тәгәрмәчтәге тиен хәлендә: катырак чапкан саен тәгәрмәч тизрәк әйләнә. Дистанциядән чыгу һәлакәткә китерәчәк. Шуңа күрә тизлекне арттырырга туры килә. Бу һәлакәтне чигерергә булыша.

Россиядә

«СЕБЕР КӨЧЕ» КЕМГӘ КУӘТ ӨСТИ

Көнбатыш базарын югалткан Россиягә Көнчыгыш державалары белән кабалалы килешүләргә барырга туры килә. Һиндстан белән нефть сәүдәсе һаман да рупия дигән киртәгә килеп бәрелә. Мәскәү рупияләрдән баш тартып, башка валюталарга күчәргә тели. Доллар һәм евро белән товар алмашу хәзер кыен: санкцияләр кыскычына эләгәсең. Дәһлигә «кара алтын»ны дирһәмнәргә сатарга теләгәннәр иде, барып чыкмады: Дубайны американнар санкцияләр белән куркыта. Юаньга Россия риза, Һиндстан каршы. Рупия исә Һиндстаннан читтә гади бер кәгазь кисәге генә. Проблема инде айлар буе хәл ителми. Европа Россия нефтен Һиндстанда эшкәртеп ала. Без дә Европа товарларын кулланабыз, әмма дус илләр аша кыйммәткәрәк китерергә туры килә. Кыргызстанга немец автомобильләре һәм запчастьлар экспорты 5500 процентка арткан, мәсәлән. Кыргызлар алай кисәк баеп, күпләп автомобиль ала башламады, безгә булышалар. Берлин белән турыдан-туры сәүдә итсәк, арзангарак чыгар иде, ләкин нишләтәсең, санкцияләр…

«Себер көче» торбасының төзелгәне һәм төзеләчәге дә Мәскәүгә кыйбатка төшә. 2024 ел бюджетыннан күренгәнчә, Кытайга зәңгәр ягулыкны уртача мең кубометрга 297,3 долларлык бәядән кудырачакбыз, ә Европа һәм Төркиягә сату бәясе – 501,6 доллар. Аннан соң килүче елда бәя тагын да төшәчәк: «Себер көче»ннән аккан газ мең кубометрга 271,6 доллар белән генә бәяләнәчәк.

Бу проблеманың яртысы гына. Россия тагын бер «Себер көче» төзи бит. Путин Кытайга баргач, торба турында килешү имзаланмады имзалануын, әмма барыбер төзергә кирәк: газны кая куясың? Пекин Россиягә кабалалы шартлар куя. Төзелеш тулысынча Россия хисабына алып барылачак, чиннар бер юань акча да бирми. Инфраструктура өчен кирәкле җиһазларның һәм материалларның 80 проценты Кытайда җитештерелергә яисә Кытай фирмаларыннан алынырга тиеш. Кытай җиреннән үтүче торбаны эксплуатацияләү 15 еллык концессия шартларында барачак, ягъни 15 ел үткәннән соң торба Кытай милкенә әвереләчәк. «Газпром»га аны арендаларга туры киләчәк. Тагын бер кызыклы шарт бар: контракт үтәлмәгән очракта түләнергә тиешле штраф депозит рәвешендә хәзердән үк Кытай банкында ятарга тиеш. Мондый шартлар, шик юктыр, Кытайга куәт өсти.

ТАПШЫРЫЛ...ГАН ХАТЛАР

Хәтер

«Яз кайтмасак, көз кайтырбыз...» – дип язган ул үзе дә. Татар җәмәгатьчелеге күренекле татар язучысы Гадел Кутуйны искә алды. Тууына 120 ел тулган көндә әдипнең Казанда яшәгән йортында яңартылган истәлек тактасы ачылды.

Мөштәри урамында урнашкан, Гадел Кутуй 1929–1942 елларда яшәгән йортта истәлек тактасы бар иде инде. Аны яңартып, әдипнең портреты төшерелгән барельеф ясаган скульптор – Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Рөстәм Габбасов.

Чарада катнашкан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов сүзләренчә, телебез язмышы, милләтебез киләчәге турында уйланабыз икән, халкыбызга хезмәт иткән кешеләр турында онытмаска кирәк.

– Бу чараның Гадел Кутуйның туган көнендә узуы – үзенә күрә бер символик күренеш. Ул – шагыйрь дә, язучы да, публицист та. Аның киңкырлы иҗатыннан «Тапшырылмаган хатлар» әсәрен генә алыйк. Тирән, фәлсәфи, кеше күңелен ярарлык эчтәлеге булмаса, аңа нигезләнеп опера да, спектакль дә куелмас иде, фильм да төшермәсләр иде. Язучыны бүген менә шул рәвешле искә алуыбыз хәер-дога булып ирешсен, – диде ул.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла әдипнең катлаулы язмышы турында искә төшерде.

– Бик мәшһүр шагыйребез, язучы, драматург, публицист, журналист Гадел Кутуй – татар әдәбиятында исемен алтын хәрефләр белән язып калдырган шәхес. Узган гасырның 20 нче елларында ул Хәсән Туфан, Кави Нәҗми белән бергә әдәбият күгенә йолдыз кебек атылып керә һәм бик актив иҗат итә башлый. «Җидегәнче»лектә гаепләнеп, тоткынлыкта булса да, сугыш елларының иң авыр мизгелләрендә дә әдәбиятыбызга хезмәт итүдән туктамый ул, – дип сөйләде Ркаил Зәйдулла.

Язмышның ачы шаяруы булгандырмы: Гадел Кутуй, сугышта яраланып түгел, сугыш тәмамланганнан соң Польшаның Згеж шәһәрендәге госпитальдә үпкә авыруыннан вафат була һәм шул шәһәрдә җирләнә. Аның кабереннән бер уч туфракны туган ягына алып кайткан әдип, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, күренекле язучы җирләнгән урынны да бөтенләй онытып бетермәсәк иде, дип теләде.

Чарада Гадел Кутуйның оныкчыклары Диана һәм Тимур, бертуган абыйсы Җиһаншаның оныгы Энҗе дә катнашты.

– Берничә ел элек без Миләүшә Айтуганова белән берлектә «Илһам» мәдәниятне үстерү фонды төзедек. Бергәләп «Мулла», «Тапшырылмаган хатлар» кебек фильмнар төшердек. Фонд татар мәдәниятен, сәнгатен үстерүгә, мирасыбызны киләчәк буыннарга тапшыруга үз өлешен кертергә тырыша, – дип сөйләде Диана ханым. – Гадел Кутуйның тормыш иптәше Галимә Садыйковнаны бик яхшы хәтерлим. Без әни белән аның янына кунакка килергә ярата идек. Алардан безгә зур әдәби мирас, күпсанлы фотоальбомнар калды. Мин аларны бик яратып балаларыма күрсәтәм, кадерләп саклыйм.

Шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин Гадел Кутуйны «табигать тарафыннан зур потенциалы булып та, чын мәгънәсендә ачылып бетмәгән шәхес» дип атады.

– Бер сәбәбе «җидегәнче»лек яласыннан иза чигүе булса, икенчесе – бик яшьли вафат булуы. Ул безнең буынга «Рөстәм маҗаралары» аша бик озак абага чәчәге эзләтте, күп кенә яшьләр өчен «Тапшырылмаган хатлар»ы белән юаныч булды, ул «Сагыну» кебек нәсерләре аша Ватанга булган мәхәббәтне танырга, аның зурлыгын аңларга ярдәм итте. Безнең бүгенге тыйнак, кечкенә тантанабыз котлы булсын, – дип сөйләде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Бердәмлек һәм эш

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Без татар халкына чиксез рәхмәтле. Өйләргә – суыткыч, укучыларга – велосипед, укытучыларга ноутбукка кадәр алып бирделәр, – дип сөйләде Йолдызда 40 елдан артык балаларга белем бирүче Гөлсинә Байтирәкова.

Ул үзе белән Казанга укучыларын да алып килгән. Форумда балаларның хыялы да чынга ашты. «Рөстәм абый, сез хәзер безнең өчен бик якын кеше. Әмма сезнең белән төшкән фотобыз гына юк», – дип җиткерде алар ихлас теләкләрен. Рәис шунда ук сабыйлар янына ашыкты.

Горурланырлык та, сокланырлык та җыен булды бу. Әстерхан эшмәкәре Лилия Габидова, мәсәлән, өч бала әнисе булу белән беррәттән, бизнес та алып бара. Бөтен Әстерханга дан тотып, балык сата ул.

– Моннан дистә еллар элек гап-гади татар авылында балык тозлап сатудан башланган эшнең еллык әйләнеше хәзер 140 миллион сум тәшкил итә, – дип сөйләде эшмәкәр. – Әстерхан урамнарындагы туристларга игътибар итсәгез, һәр өченчесе диярлек безнең балык салынган сумка-пакет күтәреп йөри. Чөнки продукцияне халыкка тәкъдим итүгә дә зур әһәмият бирәбез. 700дән артык төрдәге балык сатабыз.

Ә Алтай краенда татар токымлы атлар үрчетә башларга мөмкиннәр. Бу хакта эшкуар Әнвәр Әминов әйтте.

– Татар токымлы атларга карата кызыксынуны арттыру өчен, быел Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән Казаннан татар токымлы атларда Алтайга кадәр атка атланып бару чабышы узды. Алар илнең яртысын диярлек узды. Алтайга килеп җиткәч, атларны безнең «Карым» хуҗалыгына бүләк иттеләр. Без аларның башын 500гә кадәр җиткерергә телибез, – дип фикерләре белән уртаклашты татар эшкуары.

Ул татарларны Алтайга эшкә дә чакырды. Ә менә Төмән эшмәкәре Ринат Гайсин якын арада ук Татарстанда 80нән артык эш урыны булдырачак. «Полимергруп» оешмасы җитәкчесе республиканың Лаеш районында җылыту-изоляция материаллары заводы сала.

– Милләттәшләремә якынрак буласым килде, – ди ул эшен җәелдерүе турында. – Татарстанда бизнес өчен бөтен шартлар да бар. Республикага еш кайтып йөргәч, Төмәндә дә оешма ашханәсендә эшчеләрне җомга көннәрендә татар милли ризыклары белән сыйлый башладык.

Төмәндә үскән эшкуар туган телендә начар аралаша. Алай да: «Татар халкым, сезгә карап йөрәгем яна», – дип күңелендәгесен татарча җиткерде.

Рөстәм Миңнеханов татар эшкуарлары белән горурлануын әйтте һәм аларның татар телен белеп бетермәүләрен гаеп итмәскә кушты.

– Татар – татарча сөйләшә белгән кеше генә түгел, үз вакытында телне өйрәнә алмауга төрле сәбәпләр булырга мөмкин, иң мөһиме, без рухи яктан бер-беребезгә бик якын, – диде Рәис һәм Татарстанның ана телен өйрәнүдә һәрьяклап ярдәм күрсәтергә әзер булуын җиткерде. – Балаларыбыз, оныкларыбыз татар телен белергә тиеш. Әти-әнигә, хезмәткә һәм дингә мәхәббәт исә безнең канга сеңгән. Сез барыгыз да үрнәк күрсәтерлек кешеләр. Без сезнең белән горурланабыз. Йолдыз авылына бәйле вакыйгалар бердәмлегебезне тагын бер кат дәлилләде. Без Сабантуйларда гына түгел, авырлык килгәндә дә бергә була алабыз. Бүген хәрби операция баруын да истән чыгарырга ярамый. Милләттәшләребез илебез өчен хәлдән килгәннең барысын да эшли.

Рәис форум катнашучыларына республиканың дәүләт бүләкләрен дә тапшырды. Җыен «Туган тел» җыры белән тәмамланды. Аны залда утырган һәркем басып җырлады.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КАДЕРЛЕ ЯДКАРЬ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Татарстан Республикасы Дәүләт флагы көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне ихлас күңелдән Татарстан Республикасы Дәүләт флагы көне белән котлыйм.

Гражданнарда ватанпәрвәрлек хисе дәүләтнең символларына ихтирам белән караудан уяна. Флаг, Герб һәм Гимн хокукый һәм тәрбияви вазыйфаларны гына үтәп калмый, ә бәһасез тарихи-мәдәни мирасны да тәшкил итә, илнең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген берләштерә, аның рухи куәтенең мөһим өлеше булып тора.

Менә инде өч дистә елдан артык республикабызның йөзен өч төп рәсми атрибут – Флаг (авторы – Татарстан Республикасы халык рәссамы Т. Хаҗиәхмәтов), канатлы барс сурәтләнгән Герб (филология фәннәре докторы Н. Ханзафаров һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Р. Фәхретдинов җитәкчелегендәге авторлар коллективы) һәм «Туган ягым» шигырен (авторы – Р. Байтимеров, Ф. Пираев тәрҗемәсендә) композитор Р. Яхин җырга салган Гимн гәүдәләндерә. Борынгы җиребездә гасырлар буе яшәүче халыкларның милли-мәдәни һәм рухи традицияләрен үз эченә алган бу берләштерү символлары вакыт сынавын уңышлы узып, бүген Татарстаннан ерак җирләрдә дә билгеле һәм хөрмәткә ия.

Моннан утыз ике ел элек, 1991 елның 29 ноябрендә, Татарстан Югары Советы озакка сузылган җанлы бәхәсләрдән соң республиканың яңа дәүләт символы буларак яшел, ак һәм кызыл төсле әләмне раслады. Аның өч горизонталь буйдагы төсләре күпмилләтле халкыбызның тормышчан принципларын чагылдыра: яшел – язгы уяну, торгызу; ак – ниятләр сафлыгы; кызыл – җитлегү, көч-куәт һәм яшәү ныклыгы төсе. Бүген республикадагы һәр әһәмиятле вакыйга – халыкара очрашулар яисә рәсми сөйләшүләр, спорт чаралары һәм иҗтимагый чаралар – болар берсе дә Татарстан флагыннан башка үтми.

Кадерле ватандашлар! Безне, төрле буыннар һәм халыклар вәкилләре булуыбызга карамастан, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе язмышы, Ватаныбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен уртак җаваплылык берләштерә. Бүген шушы бәйрәм көнендә без иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендәге уңай үзгәрешләргә юнәлдерелгән зур бурычларны хәл кылуда үзебезнең катнашуыбызны тагын да ныграк тоябыз. Сезгә һәм якыннарыгызга чын күңелдән игелекле эшләрегездә уңышлар, тынычлык, бәхет һәм иминлек телим! Ышанам ки, без куелган максатларга ирешербез, Ватаныбызның бөеклеге хакына барлык ниятләребезне тормышка ашырырбыз!



Илдар Мөхәммәтҗанов

ӨРЕП КАБАСЫ

Саклык счетындагы акчагызны урларга маташканнар! Соңгы арада мошенниклар халыкка әнә шулай дип алдап шалтырата башлаган.

Алар үзләрен Үзәк банк хезмәткәре дип таныштыра, кешенең бөтен шәхси мәгълүматын төгәл әйтеп сөйләшә. Ышанмас җиреңнән ышанырга тагын бер сәбәбе бар. Алар шалтыратканда Үзәк банкның сайтта күрсәтелгән рәсми номеры чыга.

– Мошенниклар безнең хезмәткәрләр исеменнән шалтыратып, кешенең саклык счетыннан акча урларга маташуларын хәбәр итә. Акчаны саклап калу өчен телефонга махсус кушымта йөкләтеп, анда язылганнарны төгәл үтәргә куша алар. Истә тотыгыз: Үзәк банк, нигездә, финанс оешмалары эшчәнлеген көйли. Шуңа күрә безнең хезмәткәрләр беркайчан да клиентларга турыдан-туры шалтыратмаячак, – диелә Үзәк банк хәбәрендә.

Телефоннан шикле затлар белән сөйләшергә ярамавын һәркем белә анысы. Әмма телефонда банкның рәсми сайтта күрсәтелгән номеры чыккач, күпләр аптырап кала. Белгечләр исә бу очракта анысына да ышанып бетмәскә куша. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат һәм иҗтимагый элемтәләр бүлеге башлыгы урынбасары Максим Костромин сүзләренә караганда, мошенниклар теге яки бу оешма, орган исеменнән шалтыратканда номерларны алмаштыру дигән алымны куллана.

– Алар бер номердан шалтырата, ә кешегә ул теге яки бу орган, оешманың номеры булып күренә. Шуңа күрә телефон кырыгалдарлары корбаны булмас өчен иң элек 112 номерына яки «ышаныч телефоны»на шалтыратып, теге яки бу номер буенча кемнең шалтыратуын, ул сөйләгән сүзләрнең дөресме-юкмы икәнлеген белешергә кирәк. Шикле номерны шалтыратып тикшерергә уйлаган очракта, аңа телефон кенәгәсендә күренгән номерга басып кына түгел, ә шул ук саннарның һәркайсын яңабаштан җыеп шалтыратырга кирәк. Ник дигәндә, әзер номерга гына шалтыраткан очракта сез барыбер аның артына яшеренгән мошенник номерына шалтыратачаксыз, – ди ул.

Саннарга күз салсак, Россиядә ел саен 400 меңләп кеше телефон аша эш итүче кырыгалдар корбаны була. Шул рәвешле ил халкы елына 3,5 миллиард сум акчасыннан колак кага. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада көненә уртача 30 кеше телефон аша алдана.

Үзәк банк мәгълүматларына караганда, быелның өченче кварталында алар клиентлар ризалыгыннан башка 288,8 мең шикле операция башкарган. Бу ел башыннан бирле теркәлгән уртача күрсәткечтән 23 процентка күбрәк. Шикле операцияләрнең өчтән бере (31 процент) телефон аша кылынган. Шул вакыт эчендә банклар, мошенникларның эшенә каршы төшеп, клиентларының 1,7 триллион сум акчасын саклап калган. Халыкны төп башына утырту өчен кулланылган 141,8 мең телефон номеры блокка куелган.

Киләсе елдан Россиядә банкларны мошенник корбаны булган клиентларына югалткан акчаларын тулысынча кире кайтарырга мәҗбүр иткән закон үз көченә керәчәк. Әмма әгәр кеше «акча күчерергә» дигән төймәгә үз куллары белән басып, ризалык белдергән булса, аңа бу закон да ярдәм итә алмаячак, ди белгечләр. Шуңа күрә бар да һаман да шул уяулыкка кайтып кала. Шикле сылтамалар буенча кермәскә, билгесез затларга үзең турында шәхси мәгълүматны, банк картасы номерларын, смс аша килгән кодларны әйтмәскә.

Юрист Роман Архипов сүзләренә караганда, кеше билгесез затка банк картасы номерын әйтсә, аның кушуы буенча телефонга килгән кодны үз куллары белән җыйса, ул автомат рәвештә теге яки бу операцияне башкару өчен ризалык биргән булып саналачак.

– Бу очракта инде аның мошенник корбаны булуын дәлилләп булмаячак. Югалткан акчаларын да кире кайтарып булмаячак дигән сүз, – ди юрист.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«БЕЗНЕҢ ЭШ – ЕЛЫНА 365 КӨН»

АКТАНЫШ РАЙОН ЭЛЕКТР ЧЕЛТӘРЕНӘ – 50 ЕЛ

Компаниянең туган көне – коллектив белән бергә җыелып, хатирәләрне яңарту өчен менә дигән сәбәп. Актаныш районының электр челтәре дә быел үзенең ярты гасырлык юбилеена кагылышлы истәлекләрне яңарта. Актанышта РЭС оешуның рәсми датасы 1973 ел саналса да, район территориясен электрлаштыру эшләре 1948 елда ук башланган. Ул чорда Яңа Балтач авылы янында беренче гидроэлектростанция төзелә. Ә беренче Ильич лампочкалары Актанышта 1953–1954 елларда кабына. 1957 елда Сөн елгасында икенче гидроэлектростанция сафка баса. Ул ут белән Актаныш районын гына түгел, ә күрше Мөслим районын, хәтта Башкортстанны да тәэмин итә.

Үткәне

Актаныш район электр челтәренең чишмә башы 1966 елга барып тоташа. Нәкъ менә шушы елда Минзәлә район электр челтәренең Пучы авылындагы участогы ачылган. Мондагы подстанция беренче чиратта нефтьчеләргә хезмәт күрсәтә. 1968 елда – Теләкәй, 1971дә – Актаныш, ә 1973тә Байсар подстанцияләре төзелә. Шул ук 1973 елда барлык подстанцияләрне бер йодрыкка туплаган Актаныш район электр челтәре оеша.

Актаныш электр челтәренең үткәне дә, бүгенгесе дә 38 ел гомерен энергетикага багышлаган Альберт Шәйхетдиновның күз алдында. Хезмәт юлын ул 1969 елда Пучы участогында слесарь буларак башлап җибәрә. Ул чорда Пучы һәм Уразмәт участоклары Минзәлә районының электр челтәренә карый.

– Электрослесарь булып эшләгәндә, техника юк иде, – ди Альберт абый. – Бөтен булган эш коралларын «Иж-Юпитер» мотоциклына төяп йөрдек. Күпчелек эшләр кул хезмәтен таләп итте. Ышанасызмы-юкмы, кул белән чокыр казып, электр баганасын аркан белән күтәреп утырта идек. 1973 елда Актаныш район электр челтәре оешкач, эшләр бераз булса да җиңеләйде. Ике трактор сатып алдык. Әле дә хәтеремдә, кыш көне ут сүнгән очракта юлга чыгу өчен, агач чанага будка ясап куйдык. Аның эчендә җылыныр өчен тимер мич. Шушы будканы ДТ-75 тракторына тагып, авария урынына чыгып китә идек.

Хезмәт эшчәнлеген Альберт Шәйхетдинов соңрак өлкән мастер, аннан баш инженер буларак дәвам иттерә.

– 1999 елда Илшат Шәехович «Татэнерго» оешмасының генераль директоры булып килгәч, үзгәрешләр аеруча нык сизелде. Яңа техника, җиһазлар кайта башлады, эш алымнары үзгәрде, яңалыклар керде, хезмәт хаклары артты. Аңа кадәр айлар буе акча алмаган чаклар булды. Заманасы шундый иде. Хезмәт хакын да әле акчалата түгел, ә төрле товарлар белән бирәләр иде, – ди Альберт Шәйхетдинов.

1980–2012 елларда Актаныш электр челтәрендә техник, склад мөдире булып эшләгән Гөлдәрия Фәтхерахманова белән дә аралаштык. Гөлдәрия апа белән Альберт абый кебекләрне һәр оешманың аяклы тарихы, хәтер сакчылары, диләр. Ә хәтер дигәнең сандыгына күпне сыйдырган. Алар арасында күңелне сөендерә торганнары да, көендерә торганнары да шактый. Тик шулай да авыр хәлләр тирәнрәк эз калдырган.

– Элек ничек эшләгәнне искә алган саен, йөрәк кысылып куя, – дип хатирәләргә бирелә Гөлдәрия апа. – Склад мөдире булып эшләгән чорда 135 чакрымераклыктагы Түбән Камадан багана, материал алып кайтырга кирәк иде. Бензинны Чаллыдан ташыйсы. Ә юллар начар, көзен – пычрак, кышын – кар ерып, язын ташу өстеннән йөрергә туры килде. Башта карны көрәп юл ачам, артымнан ГАЗ-66 белән авылдашым Мәхмүт Хәмидуллин бара. Кара төндә бүреләр белән очрашкан чаклар да булды. Үзәккә үткән ачы җилләр, яңгырлар турында әйтеп тә торасы юк.

Еллар вакыйгалар агышына тиң. Алар алгарак барган саен, тармакта да зур үзгәрешләр башланды. Эшчеләрнең эш шартлары гына түгел, тормышлары да уңайланды. Илшат Шәехович район башлыгы булып эшләгәндә, минем өчен иң зур шатлык фатир алу булды. Аның ярдәме белән куышлы булып калдым. Шуның өчен зур рәхмәт аңа.

Ул заманнарда бит аварияләр дә, ут сүнү дә күпкә ешрак булган. Яңгыр яуса да, көчле җил булып, буран туздырса да, электр чыбыкларына зыян килеп, авылларны утсыз калдырган. Эшләгән елларда Альберт Шәйхетдиновка аларын да шактый күрергә туры килгән:

– Иң истә калганы 1988 елның декабрендә яуган карлы яңгыр булгандыр. Ул вакытта электр чыбыклары беләк калынлыгындагы боз белән капланды. Чаллыдан килә торган 110 кВ көчәнештәге линияләр арасында 13 багана ауган иде. Яңа елга кадәр аларны алыштыру, төзәтү белән шөгыльләндек.

2007 елның җәендә булып узган көчле давыл да хәтергә нык уелып калган. Ул елны нибары унбиш минутлык көчле гарасат, агачларны аударып, электр чыбыкларын өзеп, районның күпчелек авылларын утсыз калдырды. Барысын да карап, сафка бастырырга алты көн вакыт кирәк булды. Үзебезнең генә көч җитмәгәч, башка район электриклары да ярдәмгә килде.

Актаныш электр челтәре ул елларда зур чыныгу ала. Без эшләгән чорда энергетикада авыр булды, ди ветераннар. Хәзерге шартлар бөтенләй башка. Яшьләргә теләк бер. Тыныч тормышларда матур гына, хәвеф-хәтәрсез эшләргә язсын аларга.



Багана кую мизгеле.

Бүгенгесе

2000 елда Әнәк авылында яңа подстанция сафка баса. 110 кВ көчәнештәге ике линия Минзәләдән, тагын икесе – Мөслим ягыннан килеп, аларның куәте арттырыла. 2020 елның 19 августында Актаныш энергетиклары Әнәк авылындагы иске базадан Шәрип Шәймиев урамында төзелгән яңасына күченә. Ачылыш тантанасында Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә катнаша.

Актаныш район электр челтәре хәзерге вакытта 86 авылны ут белән тәэмин итә. Ә бу – 11300 шәхси хуҗалык һәм 473 юридик зат дигән сүз.

– Ничек кенә тырышып эшләсәң дә, һәр эшнең үз авырлыгы бар, – ди бүген Актаныш район электр челтәрен җитәкләүче Марат Шакиров. – Көндәлек мәшәкатьләре дә, хәл итәсе мәсьәләләре дә чыгып кына тора. Хәер, башкача булса, эшләүнең мәгънәсе дә булмас иде. Безнең күп линияләр басу уртасыннан уза. Андый участокларга хезмәт күрсәтү авыргарак туры килә. Ләкин элек башкача эшләп тә булмаган, ничек турырак булган, шулай сузылган. Аңа карамастан, без районның һәр кешесенә электр энергиясен токкарлыксыз сыйфатлы итеп җиткерергә тырышабыз. Районда яңа йортлар, биналар сафка баса, аларны тиз арада электрга тоташтыру да – безнең көндәлек бурыч. Кыскасы, безнең эш – елына 365 көн.

Электрның ни дәрәҗәдә кирәклеген хуҗалык җитәкчесеннән дә ныграк аңлаучы кеше юктыр.

– Өйдә дә, эштә дә бар нәрсә электрга бәйле, – ди 40 елдан артык «Ташкын» хуҗалыгын җитәкләүче Рәүхәт Салихҗанов. – Хуҗалык элек-электән энергетиклар белән кулга-кул тотынып эшләде. Элек бигрәк тә нык сизелә иде ул. Әйтик, электриклар Пучыдан килеп җиткәнче, без инде үзебез булдыра алганны эшли тора идек. Байсар авылындагы трансформатордан сигез хуҗалыкка электр бирелә. Әйтик, безнең тирәдә авария булса, күрше-тирәдәге хуҗалыклар шулай ук утсыз кала иде. Хәзер, билгеле, эшләрнең күпчелеге автоматлашты, авария булган участокны гына читтән торып аерып кую мөмкинлеге бар. Безнең фермаларда сыерларны роботлар сава. Бер хилафлык килеп чыга икән, бөтен система юкка чыгарга, эш тулысынча тукталырга мөмкин. Шуның өчен безнең аерым трансформатор подстанциясе, генератор тора. Электр линияләрендә планлы эшләр булгалый, әлбәттә. Андый очракларда гадәттә ун көн алдан әйтәләр. Шуңа күрә энергетикларның эшчәнлегенә карата рәхмәттән башка сүзем юк, бергә аңлашып эшлибез.

Агач баганалы линияләрдә авария була калса, чаңгы киеп, мотоциклга атланып яки ат җигеп чыгып чапкан вакытлар артта калды. Бүген югары технологияләргә ия район электр челтәре кайчандыр хыялда да булмаган зур эшләр башкара. Шуларның берсе – электрны өзмичә генә, югары көчәнеш астында эшләү тәҗрибәсен Актаныш энергетиклары да уңышлы куллана. Моның өчен районда 3 бригада бар. Актаныш РЭСында хәзерге көндә 68 кеше эшли. Шунысы сөендерә: бар җирдә дә күзәтелә торган кадрлар кытлыгы юк биредә. Шуңа күрә җитәкче үзенең кул астында эшләүче хезмәткәрләргә рәхмәтле. Шулай, тәүлек дәвамында халык хуҗалыгының иң мөһим тармагында кизү торучы энергетикларның һәркайсы мактауга лаек. Ут сүнгәндә, тиз арада килеп, проблеманы чишүчеләр дә, үзләренә йөкләнгән эшне зур төгәллек белән башкаручылар да – алар бит.

Билгеле, шушы тарихны булдырган, авыр вакытларда һөнәрләренә тугры калган хөрмәтле ветераннар да – игътибар үзәгендә.

– Безнең төп бурычыбыз – Актаныш район электр челтәренең үткәнен онытмау, тарихын саклау һәм ветераннарының хәлен белешеп тору, – ди бу уңайдан Марат Шакиров. – Мин үзем озак еллар бергә эшләгән Фәндүс Мостафинны хөрмәтләп искә алам. Аңардан соң – 2005 елда – әлеге вазыйфага мине билгеләделәр. Ветераннарыбызга – сәламәтлек, бүген эшләүче егетләребезгә яңалыкка омтылып, матур гына, җитди аварияләрсез эшләргә язсын.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сулдан уңга: Альберт Шәйхетдинов, Гөлдәрия Фәтхерахманова, Марат Шакиров, Рәүхәт Салихҗанов.

Актаныш район электр подстанциясенең хәзерге бинасы.

Көчле рухлылар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Очрашуда физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә тиешле ташламалар турында да сөйләштеләр. Республикада яшәүчеләрнең күбесе ТКХ хезмәтләр өчен бирелә торган субсидия ала икән. Быел аны алыр өчен 248 мең инвалид мөрәҗәгать иткән.

Россия Социаль иминият фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин хәбәр итүенчә, быелның сентябреннән үзенчәлекле бала тәрбияләүче әни ай саен түләүле дүрт көн ял алырга хокуклы. Киләсе елның гыйнварыннан ул елга бер тапкыр 24 көнгә дә ял сорый ала.

Киләсе ел башыннан медицина-социаль экспертиза белгечләре группа биргәндә авыруның исем-фамилиясен дә белмәячәкләр. Медик-социаль экспертизаның Татарстан буенча баш бюросы җитәкчесе урынбасары Ольга Пузанова әйтүенчә, 2022 елның 1 июленнән алар табиблар электрон рәвештә җибәргән белешмә белән эшли инде. Хәзер шәхси мәгълүматларны белмичә эшли башлыйлар.

Ольга Пузанова өлкәннәр арасында инвалидлыкка китерүче авыруларны да санады. Иң беренче чиратта бу – онкология, икенче урында – кан әйләнеше системасы, өченче урында – сөяк-мускул авырулары. Ә менә балаларга бирелүче инвалидлык сәбәпләре уйланырга мәҗбүр итә. Беренче урында – психик авырулар, икенче урында – нерв системасына бәйле тайпылышлар…

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Инвалидлык буенча социаль пенсия күләме	
1 нче группа	4306,79 сум
2 нче группа	7153,33 сум
3 нче группа	6080,38 сум
Тумыштан инвалид баланың социаль пенсиясе күләме	
1 нче группа	17167,83 сум
2 нче группа	14306,73 сум
3 нче группа	6080,38 сум
Бердәм түләү күләме (ЕДВ)	
1 нче группа	4957,95 сум
2 нче группа	3540,76 сум
3 нче группа	2834, 40 сум
Балаларга	3540,76 сум
Социаль пакет	1469,74 сум

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисенең беренче урынбасары **Сәлахетдинов** Радик Илдус улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Банк системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) идарәсе рәисе **Гәрәев** Зөфәр Фәнил улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хокук идарәсенең җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен хокукый тәэмин итү бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Белова** Лариса Викторовна, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе эш башкару бүлеге әйдәүче белгече **Камалова** Альбина Госман кызы, хезмәт ветераны **Кушмин** Шамил Әхмәтҗан улы, «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) Корпоратив бизнеска сатулар дирекциясе Корпоратив бизнес буенча Чаллы төбәк үзәгенең корпоратив бизнесны үстерү буенча директоры **Новичкова** Марина Николаевна, хезмәт ветераны **Шувалов** Григорий Елисеевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, әтисе

Хәбиров Ирек Гасый улы

кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты аналитика бүлеге мөдире Хәбиров Марат Ирек улының авыр кайгысын уртаклаша.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы милли сәхнәбезнең якты йолдызларыннан берсе, халкыбызның яраткан артисткасы, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

Наилә Хәким кызы ГӘРӘЕВАның

вафат булуы турында хәбәр итә һәм мәрхүмәнең туганнары, дуслары, якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Татар театрының күренекле артисткасы, сәнгатькә тугрылыклы булган дустыбыз, сәхнәдәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

Илсур Гыймадетдинов

Илнар Закиров

Илназ Рамазанов

Динар Кәримуллин

Рафаэль Кәлимуллин

Фаяз Зарипов

АЙРАТ БЕЛӘН БАС ЯНӘШӘ!

РАИЛ НУРГАЛИЕВ УНЫНЧЫ МӘРТӘБӘ ЧЕМПИОН ИСЕМЕН ЯУЛАП, ГЫЙЛАЕВ ҺӘМ МУХАМОВНЫ КУЫП ТОТТЫ

«Татар-информ»

Милли көрәш

Батырларга тәүге мәртәбә 100әр мең сум акча түләнгән ярышта Лаеш көрәшчеләре өстен чыкты. Алар икенче ел рәттән Татарстан чемпионатында командалар беренчелеген отты. Ярыштан репортажны укып, Раил Нургалиевның рекордчылар сафына кушылуы, Илмир Төхфәтуллинның китүе, ә Радик Сәлаховның кайтуы турында белә аласыз.

Сәләт кенә аз

Быелгы чемпионатта 40 командадан 346 егет бил алышты. Күбрәк булган вакытлар да бар иде. Шөкер итик, җәмәгать! Үстерү турында купшы сүзләр әйткәнче, булганны саклау турында уйлыйсы иде. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Көрәш федерациясе башлыгы Марат Әхмәтов та шундый фикер әйтте ачылу тантанасыннан соң.

– Көрәшебез, сөбханалла, бар. Югалтмыйбыз, саклыйбыз. Үстерәбез дип әйтергә куркам. Чөнки республикада спорт төрләре арасында көндәшлек бик көчле. Үсмерләрнең сайлау мөмкинлеге бик зур. Егетләребезгә дә: «Син көрәш белән генә шөгыльлән», – дип әйтеп булмый хәзерге заманда, – диде ул. – Әмма татарлыгыбызны, рухыбызны, эчке көчебезне, тел, әдәбият һәм сәнгать янәшәсендә көрәшне дә бергәләп сакласак, милләтебезнең киләчәген матур итеп күрә алабыз әле. Көрәшебез авыллардан район үзәкләренә, шәһәргә күчә бара. Авылларда яшьләр кими. Район үзәкләре, шәһәрләр белән күбрәк эшләсәк, андагы җитәкчеләрнең милли рухын уятып, аларны да бу эшкә җәлеп итә алсак, киләчәгебез бар.

Киләчәк булсын өчен, шартлар да кирәк. Анысы төрле урында төрлечә. Шул ук Лаеш яки Чаллыдагы шартларны ярышка команда җыя алмый интеккән районнар белән чагыштырып булмый. Аермасы бәйге нәтиҗәләрендә күренә.

> **Бүген көрәштә «килде, күрде, җиңде» кагыйдәсе эшләми. Уңышка ирешү өчен, егетләрнең Ходай биргән сәләте янына тренер үҗәтлеге, җирле җитәкчеләрнең мөнәсәбәте һәм команда рухы кирәк.**

Әлбәттә, мәсьәләнең матди ягы да бар. Бу юлы федерация батырларга зур бүләк ясады. Чемпион калган егетләргә 100әр мең сум күләмендә акча өләштеләр. Икенче урын алучылар – 70әр, ә өченче булучылар 50шәр мең сумга ия булды. Рәсми ярышларда моңарчы күрелмәгән суммалар! Көрәшнең башка төрләрендә күз алдына да китереп булмый. «Футбол белән хоккейда барыбер күбрәк түлиләр», – дип әйтүчеләр булыр. Әйтәләр дә. «Рубин» яки «Ак барс»та уйнаган берәр танышың бармы?» – дип сорагач, никтер җавап бирмиләр. Шөкер итик!

Көттереп килгән җиңү

60 килолы егетләр бәйгесендә 3 ел рәттән Алексей Абрамовка тиңнәр булмады. Тумышы белән Алексеевск районыннан булган 23 яшьлек егет соңгы ике елда Лаеш районы данын яклый. Быел да үз ишләре арасында фаворитлардан саналды ул. Әмма рәттән 4 нче җиңүне яуларга насыйп булмаган икән. Финалда Кукмара егете Илсур Гыймадетдинов бу юлы көчлерәк икәнен раслады. Тәҗрибә яшьлектән өстен чыкты. Келәмдә төрлесен күргән Илсурга көттереп килгән җиңүләренең берсе бу. Аңа ничек ирешкәнен үзе генә белә бу егет.

Алексей Абрамовның дусты һәм якташы Илнар Закиров Чистай районы данын яклап бил алыша. Ул да финалга чыкты һәм 65 килолы егетләр арасындагы хәлиткеч алышта былтыргы чемпион, Лаеш командасы вәкиле Илназ Димиевне җиңде.

Остаз шәкерттән калышмый

Шулай итеп, Лаешның рәттән ике көрәшчесе финалда оттырырга мәҗбүр булды. «Җитәр, көмеш артыкка китте, алтын кирәк, район башлыгы белешеп тора», – диде тренерлары. «Эшлибез аны», – диде егетләр. Башта Илназ Рамазанов 70 килолы көрәшчеләр финалында Балтачтан Илнар Муллахмәтовны отты. Сүз уңаеннан, бу ярышта Илназның тренеры булып Динар Кәримуллин саналды. Остаз шәкертеннән калыша алмый бит инде. Динар 75 килога кадәрге авырлыкта Әлмәттән былтыргы чемпион Рафаэль Билдановтан көчлерәк икәнен раслады. Шулай итеп, Лаеш егетләре ике көмеш һәм ике бронза янына ике алтынны салып куйды.

Киләсе ике категориядә исә Лаеш егетләре медальсез калды. 80 килолы егетләр ярышында Кукмарадан Марат Кәримуллинны отып, батыр исемен Әлмәт көрәшчесе Рафаэль Кәлимуллин яулады. 85ләр арасында Арча егете Фаяз Зариповка тиңнәр табылмады. 25 яшьлек көрәшчегә бер-ике ел эчендә зур сынаулар аша узарга, зур янгыннан соң йорт-җир мәсьәләсен кайгыртырга, әнисен соңгы юлга озатырга туры килде. Әмма бирешми егет, тормышта да, келәмдә дә нык тора.

Авырлыгы 90 килодан артмаган егетләр финалында келәмгә янә Лаеш көрәшчесе чыкты. Раил Сәлахетдинов – тумышы белән Киров өлкәсеннән, берничә ел Кукмара данын да яклады. Аның келәмдә үз-үзен тотышы беркемне дә битараф калдырмый. Ут егет, кыскасы. Әмма өстенә салкын су сибүчеләр дә табыла. Бу юлы сабырлык тантана итте. Чемпион исемен Әлмәттән Айрат Сәмигуллин яулады. 100 килолы көрәшчеләр ярышын Илмир Төхфәтуллин отты. Балык Бистәсендә туып-үскән егет күп еллар Казанның Яңа Савин районы командасы данын яклады. Рәсми бәйгеләрдәге соңгы җиңүләрен исә Лаеш районы белән яуларга насыйп булган икән. Татарстан чемпионатларындагы 9 нчы җиңүен яулагач, егет кабат келәмгә чыкмаячагын игълан итте. Тамашачы күңеленә иң тыйнак батырларның берсе булып кереп калган чемпион Сабан туйларында көрәшми калмас әле.

Чаллы хыялы

Раил Нургалиев Татарстан чемпионы булып 10 нчы мәртәбә танылды. Хәзер ул – рекордчылар сафында. Чаллы батыры Айрат Гыйлаев белән Казан пәһлеваны Рөстәм Мухамовның унар җиңүе бар. Теләче егете тәүге җиңүен 2006 елда яулады. Аннары 2007дә, 2008дә, 2010да, 2011дә, 2012дә батыр булып танылды. Бераз ял итеп алганнан соң 2016да, 2018дә, 2019да чемпион исеменә иреште. Соңгы елларда аңа Татарстан чемпионатында беренче булу бәхете татымады. Рәсми ярышларда авырлыгы 115 килодан артмаган егетләр өчен яңа категория барлыкка килгәч, Раилгә кабат бәхет елмайды. Быел ул янә Татарстан чемпионы! Теләче батырының 11 җиңү яулап, беренче урынга чыгарга тырышасына шик юк.

Сүз уңаеннан, Раилгә – 37 яшь. Ә Зәйдән Радик Сәлахов 30да гына әле. 130 килолы көрәшчеләр арасында җиңү яулап, 9ар мәртәбә чемпион исеменә ия булган батырлар сафына кушылды ул. Алар – Татарстан Көрәш федерациясенең хәзерге башкаручы директоры, Әтнә данын яклаган Марсель Таһиров һәм Әлмәт батыры, мәрхүм Ильяс Галимов.

Әлмәт димәктән, нефтьчеләр башкаласы белән Зәй арасы нибары 50 чакрым чамасы гына. Кайчандыр шул юлдан йөри башлаган Радик Сәлахов, бөтен республиканы урап, Лаеш һәм Чаллы аша кабат Зәйгә кайтып җитте. Озаккамы? Өстендә әле дә Әлмәт командасы футболкасы, ә эш урыны – Чаллыда. Чаллы димәктән, авыр үлчәүдә шушы команда вәкиле Ранис Гыйлаҗетдинов батыр калды. Ул да, Радик та иң нәтиҗәле тренерларның берсенә әверелгән Илнур Хәйбуллин җитәкчелегендә шөгыльләнә.

Язмадан чамалагансыздыр инде: әйе, командалар беренчелеген Лаеш командасы отты. 3 алтын, 3 көмеш, 2 бронза медаль алып кайтып китте алар. Иң яхшы көрәшчеләрне кайчандыр үзләренә җыярга тырышкан Әлмәт бу юлы икенче булды. Чаллыга исә өченче урын белән канәгатьләнергә туры килде. Әмма лидерлыкны кире кайтару турындагы хыялларыннан баш тартмый. Тагын бер хыяллары бар әле. Анысын әйтми торыйк.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

«Сөенгән арада елап та ала»

ЧЕМПИОННАР ИҢ КАДЕРЛЕ КЕШЕЛӘРЕ – ӘНИЛӘРЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘДЕ

Раил НУРГАЛИЕВ, Теләче районының Олы Кибәхуҗа авылыннан Рәзилә ханымның улы:
– Беләбез бит инде, һәр әни үз баласы өчен борчылып тора. Шуңа әниемне һәрвакыт сөендерергә тырышам. Әле бүген генә ике мәртәбә шалтыратып, хәлен белештем. «Әни, мин финалда, әни, мин җиңдем», – дип хәбәр итеп тордым. Барлык әниләрнеке кебек, аның да күңеле нечкә. Сөенгән арада елап та ала. Әлбәттә, минем җиңүләрдә аның да өлеше зур. Без кешедән калышмасын, бар нәрсәбез дә булсын дип, фермадан кайтып кермәде. Көне-төне эштә булды. Шуңа күрә бу җиңүем дә әниемә бүләк булды.

Радик СӘЛАХОВ, Зәй районының Сармашбаш авылыннан Ләйсән ханымның улы:
– Беләсез бит инде, әтиебез тренер иде. Әмма безнең көрәшче булып китүебездә әниебезнең дә өлеше зур. Ул гел ярдәм итеп, киңәшләрен биреп торды. Җиңелгән чакларда бигрәк тә. Оттырып кайткач, кабат көрәшкә бармыйм, дип көйсезләнгән вакытлар да булды. Әни исә безне көйли, тынычландыра иде. Әле дә кирәк чакта сүзен әйтә. Кайсы гына турнирда булмасын, без аның белән һәрвакыт элемтәдә.

Илсур ГЫЙМАДЕТДИНОВ, Кукмара районының Байлангар авылыннан Нурисә ханымның улы:
– Әйе, көрәшчеләрнең әниләре бик борчыла. Табып үстергән баласы имгәнмәсен дип куркалар. Минем әни бу мәсьәләдә бераз тынычрак. Әти дә көрәшче булгач, аның өчен гадәти нәрсә инде ул. Әмма ярышка чыгып китә башласак, сау-сәламәт әйләнеп кайтуыбызны теләп тора. Хәтерләсәгез, ике ел элек Минзәләдә Муса Җәлил бәйгесендә җиңүемне әле яңа гына дөньяга килгән кызыма багышлаган идем. Ә бәйрәм алдыннан Татарстан чемпионы исемен яулавым әнием хөрмәтенә булсын!

Илмир ТӨХФӘТУЛЛИН, Балык Бистәсе районының Биектау авылыннан Гөлшат ханымның улы:
– Спортка мине әти кертеп җибәрде. «Улым, синең бер эшең дә юк. Шуңа күрә укуда һәм спортта тырыш», – дип еш кабатлый иде. Әни ашатты-эчертте һәм мине спортка кереп китәрлек итеп үстерде. Әлбәттә, һәр әни баласының җиңүләренә сөенә. Минем әни дә шулай. Әмма мин көрәшкәнне карамый, бик борчыла. Мин исә аның борчуларын җиңү белән киметергә тырыштым.

Чемпионнар һәм призерлар

•60 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Илсур Гыймадетдинов (Кукмара)
2 урын – Алексей Абрамов (Лаеш)
3 урын – Илфат Миңнегалиев (Лаеш), Алмаз Җиһангәрәев (Түбән Кама)

•65 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Илнар Закиров (Чистай)
2 урын – Илназ Димиев (Лаеш)
3 урын – Салават Әхмәтгалиев (Арча), Алмаз Миңнехуҗин (Әлмәт)

•70 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Илназ Рамазанов (Лаеш)
2 урын – Илнар Муллахмәтов (Балтач)
3 урын – Артур Хәкимов (Тукай), Ислам Фәләхов (Алабуга)

•75 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Динар Кәримуллин (Лаеш)
2 урын – Рафаэль Билданов (Әлмәт)
3 урын – Мөнир Галләмов (Теләче), Илсаф Ишмөхәммәтов (Лаеш)

•80 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Рафаэль Кәлимуллин (Әлмәт)
2 урын – Марат Кәримуллин (Кукмара)
3 урын – Айнур Нургалиев (Мамадыш), Ринат Мингалиев (Чаллы)

•85 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Фаяз Зарипов (Арча)
2 урын – Алмаз Сәетов (Теләче)
3 урын – Рөстәм Сәлахов (Чаллы), Тамирлан Керефов (Чистай)

•90 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Айрат Сәмигуллин (Әлмәт)
2 урын – Раил Сәлахетдинов (Лаеш)
3 урын – Айдар Әхмәтов (Яшел Үзән), Руслан Зыятдинов (Чистай)

•100 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Илмир Төхфәтуллин (Лаеш)
2 урын – Илнар Галимов (Алабуга)
3 урын – Рөстәм Сираҗиев (Балтач), Рәсим Шириев (Әлмәт)

•115 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Раил Нургалиев (Теләче)
2 урын – Айнур Сыртаев (Чистай)
3 урын – Рамил Фәршатов (Зәй), Айдар Алтынбаев (Әлмәт)

•130 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Радик Сәлахов (Зәй)
2 урын – Ринат Дәүләтшин (Кукмара)
3 урын – Илмир Хәсәншин (Түбән Кама), Айназ Билалов (Лаеш)

•130 килодан югары үлчәү авырлыгы:
1 урын – Ранис Гыйләҗетдинов (Чаллы)
2 урын – Ильяс Газизуллин (Чаллы)
3 урын – Фирдүс Зәйнуллин (Яңа Савин), Газинур Шаһабиев (Кукмара)

Айрат Сәмигуллин

Илмир Төхфәтуллин

Раил Нургалиев

Радик Сәлахов

Ранис Гыйләҗетдинов

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13584 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 359

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+